ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӘМӘКӘЙ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

# Әдәби сөйләм һәм аның стильләре


I квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбият укытучысы
Хәнипова Гөлүзә Гариф кызы


2013 нче ел

# Әдәби сөйләм –

***билгеле бер телдә сөйләшүче кешеләрнең , гасырлар буена урнашып килгән таләпләрне бозмыйча, фикерне аңлаешлы һәм төгәл итеп җиткерүләре ул.***

**Сөйләм стиле –** ***язганда яки сөйләгәндә, алга куелган максатка яраклы рәвештә тел-сурәтләү чараларыннан файдалану үзенчәлекләре ул.***

# Сөйләм стиленең төрләре

*1 – әдәби стиль*

*2 – публицистик стиль*

*3 – фәнни стиль*

*4 – рәсми стиль*

*5 – сөйләмә стиль (хатлар стиле)*

Стиль –
1. Сәнгатьтә билгеле бер чорның, юнәлешнең яки аерым авторның иҗат эшчәнлегенә хас булган үзенчәлекләр
2. Берәүнең эш алымнарына, берәр төрле эшчәнлек өлкәсенә хас билгеләр
3. Тел, сөйләм чараларыннан, мөмкинлекләреннән файдалану алымнары

# Әдәби стильнең үзенчәлекләре

- - әдәби телнең нигезен тәшкил итә,
- -башка стильләргә караганда күбрәк кулланыла,
- -әдәби тел нормалары бу стильдә эшкәртелә,
- -бу стиль белән барлык әдәби әсәрләр языла,
- -әдәби стильдәге әсәрләрдә кулланылучы сүз, сүзтезмә һәм җөмләләр эстетик хис тәрбиялиләр (матурлык тойгысы уяталар),
- -һәртөрле сурәтләү чаралары (эпитет, метафора, чагыштыру, гипербола һ.б.) күбрәк кулланыла,
- -персонажларның кара-каршы сөйләшүләре (диалог) кулланыла,
- -халык авыз иҗаты әсәр тукымасына кертелә,
- -аерым персонажларның тел үзенчәлекләренә урын бирелә (диалекталь, һөнәрчелек һ.б.ш. сүзләр кулланыла).

# Публицистик стиль

- -бу стильдә газета-журнал мәкаләләре, тәнкыйть материаллары, өндәмәләр, юлъязмалар, очерк, фельетон, репортаж, памфлет, рецензия, ачык хат иҗат ителә
- -төп максаты – яңалыкны хәбәр итү, авторның уй-фикерләрен халыкка җиткерү
- -аларда иҗтимагый вакыйгалар, икътисади таләпләр чагылдырыла, аларга бәя бирелә
- фикереңнең хаклыгына ышандырырлык сурәтләү чаралары, сүзләр кулланыла
- -сәясәткә караган терминнар һәм төрле кичерешләрне (ирония, нәфрәт, үз итү) белдерүче сүзләр куллану
- һәркемгә аңлаешлы, гади, үткен тел белән язылуы шарт
- публицистик текстларның төп компонентлары - факт, фикер, аргумент, проблема. концепция, нәтиҗә.

# Рәсми стиль

- Юридик эш кәгазьләре, карар, беркетмә, гариза, аңлатма, ышаныч язуы, акт, резюме, белдерүләр языла
- Һәркайсында үзенә бер хас калып белән сүзләр кулланыла
- Озак еллар дәвамында үзенең тотрыклылыгын саклап килә

# Фәнни стиль

- Гыйльми мәкалә, китаплар, белешмә, дәреслекләр, диссертацияләр языла
- Махсус фәнни терминнар күбрәк кулланыла, сүзләр туры мәгънәсендә бирелә
- Кереш сүзләр күп урын ала, аныклагычлар еш кулланыла
- Хәбәре төшем юнәлешендәге, III зат күплек сандагы фигыль белән белдерелгән гади җөмләләр кулланыла
- Мөнәсәбәтле сүз, теркәгеч аша бәйләнешкә кергән иярченле кушма җөмләләр дә билгеле бер үзенчәлек бирә

# Сөйләмә стиль

- Көндәлек аралашу вакытында кулланыла
- Башлыча диалог (кара-каршы сөйләшү) формасында төзелә
- Гади, ким җөмләләр, һәр кешегә аңлаешлы сүзләр күбрәк урын ала
- Алдан уйланып язылмый, аралашу барышында ясала, телдән сөйләү формасында яши
- Персонажларның үзара сөйләшүе формасында матур әдәбиятта һәм хатлар язганда кулланыла.

# Белемегезне тикшерегез

- 1.Нәрсә ул әдәби сөйләм?
- 2. Стиль сүзен нинди очракларда кулланалар?
- 3. Хәзерге татар сөйләме нинди стильләрне үз эченә ала?
- 4. Стилистика фәне нәрсә өйрәнә?
- 5. Һәр стильгә хас булган төп үзенчәлекләрне санап чыгыгыз.

# Файдаланылган әдәбият


- 1. М.З.Зәкиев, С.М. Ибраһимов.Татар теле. 9нчы сыйныф өчен дәреслек. 2008 нче ел.
- 2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. II том. 1979 нчы ел.